Фәрит ХАТИПОВ

# Моңлану



КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2003

УДК 78
ББК 85.314
Х 36

**Хатипов Ф. Х.**

Х 36 Моңлану.— Казан: Татар.кит.нәшр., 2003.— 112 б.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор Фәрит Хатиповның яңа китабына төрле елларда язылган, халык арасында популярлашкан җырлары тупланды.

Нотное издание

**Хатипов** Фарит Ханафиевич

**ВДОХНОВЕНИЕ**

(на татарском языке)

Музыкаль редакторы *И.И.Байтирәк.* Редакторы *Р.М.Касыймова.*
Рәссамы *Р.Х.Хәсәншин.* Бизәлеш редакторы *Р.Г.Шәмсетдинов.*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучы *А.С.Газизҗанова.*
Корректоры *М.Ш.Хәйруллина*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 3.10.2003. Форматы $70\times100^1/_{16}$.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 9,10.
Шартлы-буяу оттиск 9,75. Нәшер-хисап табагы 8,49.
Тиражы 1000 данә. Заказ Я-671.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур.,2.

ISBN 5-298-01352-XI © Татарстан китап нәшрияты, 2003

## АВТОР ТУРЫНДА

*Фәрит Хатипов исеме җыр сөючеләргә яхшы таныш. Ул күренекле җырчыларыбыз белән озак еллар эшләп, милләттәшләребез яшәгән төбәкләрдә чыгышлар ясап танылa. Җыр язу сәләте аның тормышында көтмәгәндә барлыкка килми, әлбәттә. Музыкант күңелендә моңа кадәр ишетелмәгән аһәңнәр, интонацияләр туа икән, алар, һичшиксез, яшәргә тиеш. Композиторларыбыз әсәрләрен, халык көйләрен күп уйнаган баянчының һәрбер башкарылган әсәрне үзенчә кабул итеп, үзенчә яңгыраш биреп уйнавы күңелендә туган моңнарны җыр итеп гәүдәләндерүгә китерә. Аның бүген 300 гә якын җыры бар. Шуларның йөздән артыгы Татарстан радиосы фондында сәнгать осталары, үзешчән башкаручыларыбыз, хор коллективлары башкаруында магнитофон тасмасына язылганнар.*

*Композитор балалар өчен дә иҗат итә. Аның әсәрләре балалар өчен җыр дәреслекләренә кертелгән.*

*Фәрит Хатипов күренекле шагыйрьләр белән бергәләп иҗат итә. Г.Афзал, И.Юзеев, Ф.Яруллин, Зөлфәт һәм билгеле инде, Г.Зәйнашева аның иң яраткан шагыйрьләре. Ә композиторларыбыздан ул бигрәк тә С.Садыйкова һәм Р.Яхин иҗатын бүген дә үз кыйбласы итеп яши.*

*Аның әсәрләре берничә буын җырчылары тарафыннан яратып башкарылалар, тыңлаучыны уйландыралар, куандыралар, рухландыралар. 1970 нче елларда Зөлфәт сүзләренә язылган «Һаман яратам», Г.Афзал шигыренә иҗат ителгән «Гөлнарым», Х.Туфан сүзләренә рухланып язылган «Синең нурың» җырлары хәзерге көндә дә популяр. Шулай ук, «Моңлану» (Ф.Сафин сүз.), «Сау бул инде» (Р.Вәлиев сүз.), «Соңгы сөю» (Т.Хәләф сүз.), «Туганыма» (Ф.Гыйльфан сүз.), «Җилфер-җилфер җил искәндә» (Ә.Ерикәй сүз.) һ.б. җырлары күңел җылысын биреп язылганнар. Фәрит Хатипов Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшләү дәверендә иҗат мәктәбе уза. Казанның зур сәхнәләрендә чыгышлар ясый ул. Ә моның өчен тәвәккәллек тә, үз-үзеңә ышану да, тыңлаучының мөнәсәбәтен дә яхшы белү зарур. Авторның иҗат чишмәсе саекмасын, җыр сөючеләрне яңадан-яңа халыкчан җырлары белән куандыру насыйп булсын аңа.*

Рафаэль Ильясов,
Татарстан радиосы музыкаль тапшырулар редакциясе җитәкчесе,
Татарстанның халык артисты

# *Ярый ла син бар, туган як*

*Мизхәт Хәбибуллин* шигыре




Ярый ла син бар, туган як,
Читләрдә сагынырга.
Яшел бөдрә талларыңа
Мөмкин тик табынырга.

Ярый ла син бар, туган як,
Моңнарым уятырга.
Төшләргә кереп, балам, дип,
Кайгыдан юатырга.

Ярый ла син бар, туган як,
Сабыйдай сыенырга.
«Кайтам»,— дип,
җирсеп-җилкенеп,
Юлларга җыенырга.

# *Синең нурың*

*Хәсән Туфан* шигыре




Кояшта тудың микән,
Йолдызда тордың микән?
Өйгә ай кергәнме, дисәм,
Ул синең нурың икән.

Кигәннәрең ал икән,
Гөләп белән пар икән.
Алны уңмый, диләр иде,
Халык сүзе хак икән.

Керфекләрең кагасың,
Моңсу гына багасың.
Ай кояштан нурлар ала,
Ә син каян аласың?

# Һаман яратам

Зөлфәт шигыре




Шик туса кинәт җаныңда әгәр,
Йә килсә сиңа куркыныч хәбәр
Мин йөргән яктан, ерак-ерактан,
Ышана күрмә, һаман яратам.
Ашыга күрмә, ялгыштан саклан,
Һаман яратам, һаман яратам!

Йолдызлы аяз күгеңне әгәр
Авыр болытлар каплап китсәләр,
Каршы искән җил капланса тынга,
Нык бул, син генә, тик син җанымда.
Бирешә күрмә сагышка, моңга,
Җанымда тик син, тик син җанымда.

Сакла сөюне, таплама берүк,
Олы хисләрне ваклама берүк.
Узар гомерләр аккан су кебек,
Гомер бер генә, сөю мәңгелек.
Узар гомерләр искән җил кебек,
Сөю мәңгелек, сөю мәңгелек.

## *Гөлнарым*

*Гамил Афзал* шигыре







Сандугачтай сайрап уйнадың да
Кына гөлләренә кунмадың.
Гөлнарым,
Үкенечкә ярым булмадың.

Яулыгыңны болгап җырладың да
Йөрәкләрне телдә моңнарың.
Гөлнарым,
Борылмалы киткән юлларың.

Сине сагынып уйлар уйладым да
Чишмә буйларыннан урадым.
Гөлнарым,
Күз алдымда зифа буйларың.

## Мәхәббәт сагышы

*Татар халык* сүзләре



# МОҢЛАНУ




Җилләр исә, җилләр исә,
Сындыра талларымны.
Чит җирләрдә ялгыз башың,
Белалмыйм хәлләреңне...

Без яратып җиккән атлар —
Кара белән тимер күк.
Сагынганда айга карыйм —
Ай да ялгыз минем күк.

Күзләр җитә, кошлар китә,
Карап калам кошларга.
Очар идем яннарыңа,
Юк канатым очарга.

Сагыш бетсен, яшьләр кипсен,
Шатландырыр сүзең әйт.
Язма сәлам, җибәрмә хат,
Бик сагындым, үзең кайт.

# Сау бул инде

*Разил Вәлиев* шигыре





Мәхәббәттән өмет өзгән чакта
Синең белән нигә кавыштым?
Сау бул инде, шушы кавышуым
Булса иде соңгы ялгышым.

Кавыштырмый икән уртак кайгы,
Кирәк икән уртак хыяллар.
Сау бул инде, сөю бакчасында
Бар агачлар яфрак койганнар.

Кешеләргә яз китергән сөю
Миңа бирде көзләр сагышын.
Сау бул инде, соңгы мәхәббәтем,
Сау бул инде, соңгы ялгышым.

## Авыл кызы

*Данис Хәбибуллин* шигыре




Авыл кызы, назлы карлыгачым,
Чын күңелдән сине сөйдем мин.
Бүген тагын кичен,
Сине күрер өчен,
Бакчагызга сагынып килдем мин.


Ак пәрдәләр элгән тәрәзәңдә
Таңга кадәр янды утларың.
Йөрәк ярсып типте,
Күңел сине көтте,
Яннарыма нигә чыкмадың?

Сиңа сөйләр кайнар хисләремне
Иң түрендә саклыйм хәтернең.
Мин аларны кабат,
Күзләреңә карап,
Бары сиңа гына әйтермен.

## Яшәрәсең, Казан, яңарасың

*Гөлшат Зәйнашева* шигыре






Борынгы булсаң да картаймыйсың,
Нинди кодрәтләрдән дәрт аласың?
Әллә чибәр кызларың яшәртә? —
Яшәрәсең, Казан, яңарасың.


Иман нуры иңде — айлы иттек
Изге Сөембикә манарасын,
Саклап борынгы гүзәллегеңне
Яшәрәсең, Казан, яңарасың.


Мәңгелеккә булсын диеп салыйк
Кол Шәриф мәчете нигез ташын.
Яңа-яңа мәчетләрең белән
Яшәрәсең, Казан, яңарасың.

Асыл ир-егетләр акыл белән
Алып бара бүген заманасын,
Хезмәт сөйгән халкым көче белән
Яшәрәсең, Казан, яңарасың!..

# Теләче

*Гөлшат Зәйнашева* шигыре






Мишә буйлап еракка нур сибә
Теләчедә аткан алсу таң.
Китсәм ерак,
жырлыйм мин моңаеп,
Мишә буен өзелеп сагынудан.

К у ш ы м т а :

Мишә буе, Мишә буе,
Мишә буе тал гына.
Теләченең чишмәләре,
Эчим дисәң, бал гына.
Мишә буйлары тал гына,
Тал яфрагы бал гына.
Баллы яфрагың булырмын,
Яннарымда кал гына.

Ай калыкмаса да, айлы кебек
Теләченең зәңгәр төнендә.
Теләченең үз ае, йолдызы
Балкый микән әллә күгендә?

К у ш ы м т а .

Теләчедә нигә шулай икән? —
Кешеләрнең йөзе яктырак.
Теләченең кырларында үскән
Икмәге дә тәмле, татлырак.

К у ш ы м т а .

# Шулай шул

*Роберт Миңнуллин* шигыре





Икәү эчкән чишмә шул ук,
Икәү тапкан тугай шул.
Тик үзебез генә, менә,
Үзгәргәнбез бугай шул…
Шулай шул,
Шулай шул,
Үзгәргәнбез бугай шул…

Без үзебез үзгәрсәк тә,
Кырда шул ук тургай шул.
Әле дә бер-беребезне
Яратабыз бугай шул…
Шулай шул,
Шулай шул,
Яратабыз бугай шул…

Һавада икәү сокланган
Шул йолдызлар, шул ай шул.
Андый кичләр, андый хисләр
Онытылмый бугай шул…
Шулай шул,
Шулай шул,
Онытылмый бугай шул…

# *Гомер бер генә кимлә ул*

Каракалпакстанның халык шагыйре *Таҗетдин Сәетҗанов* шигыре. *Зәки Нури* тәрҗемәсе




Гомер бер генә килә ул,
Мәгънәле яшәү кирәк.
Һәркемнең дә күкрәгендә
Тибә бер генә йөрәк.

Кушымта:
Гомер җыр була ала ул,
Таба алсаң үз көен.
Илең син диеп сөенсен,
Син илең өчен сөен.

Һәркемнең дә тормыш юлы
Булмый гел шома таштан.
Юл уңа, әгәр сукмакны
Тик үзең эзләп тапсаң.

Кушымта.

Гомер бер генә килә ул,
Кыю мен үрләренә.
Якын дусларың булсын ул
Табының түрләрендә.

Кушымта.


## *Газинур урманы*

(Хор өчен)

*Советлар Союзы герое Газинур Гафиятуллинга багышлана*

*Гөлшат Зәйнашева* шигыре

**Tempo di marcia**






Урманчы булган Газинур,
Урманнарга җырлап кергән.
Ак каеннар арасында
Кошлар моңын тыңлап йөргән.

К у ш ы м т а:

Газинур урманын кичтем,
Җәйнең матур бер таңында.
Үзәкләрне өзеп-өзеп,
Кәккүк кычкырган чагында.

Ак каеннар белә микән,
Кәккүк тавышы нигә серле?
Кәккүк моңына күчкәндер
Газинурның газиз гомере...


К у ш ы м т а.

Урманчы булган Газинур,
Урманнарга җырлап кергән.
Ак каеннар арасында
Кошлар моңын тыңлап йөргән.

К у ш ы м т а:
Ак каеннар белә микән,
Кәккүк тавышы нигә серле?
Кәккүк моңына күчкәндер
Газинурның газиз гомере...

# Таңсылу

*Мәхмүт Хөсәен* шигыре







Күктә — Зөһрәкәй,
Җирдә син чибәр.
Сокланып сиңа:
«Таңсылу!» — диләр.
Син чишмәдәй саф,
Син гөлдәй гүзәл!
Сине күрмичә
Нинди җан түзәр?!


Таңда уянгач,
Сагынып сине,
Тәрәзәм кага
Мәхәббәт җиле.
Йөрәгем хәлен
Аңла, Таңсылу,
Синсез үткән көн —
Сыкрап җан сулу...
Аңла, Таңсылу!

# *Себер җирләре – илнең бизәге*

(Хор өчен)

*Мидхәт Миншин* шигыре






Себер юллары
Булган моң-зарлы.
Әле дә онытылмый
Богау чыңнары.

Инде ул көннәр
Калды еракта.
Өр-яңа җырлар
Туа бу якта.

Себер җирләре —
Илнең бизәге.
Монда килмичә
Йөрәк түзәме?

Килә Бөгелмә,
Килә Минзәлә,
Изге ашкыну
Балкый йөзләрдә.

Дан алган ирләр
Әлмәт, Шөгердә,
Нефть чыгара
Бүген Себердә.

Себер җирләре —
Илнең бизәге.
Монда килмичә
Йөрәк түзәме?

Эшкә-ярышка
Нинди киң мәйдан.
Себер үзе дә
Туа яңадан.

Ерак елларга
Бүләк булыр ул,
Килер көннәрне
Зурлап торыр ул.

Себер җирләре —
Илнең бизәге.
Монда килмичә
Йөрәк түзәме?

# *Шушы яктан, шушы туфрактан без*

*Клара Булатова* шигыре





Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Китә калсак үзгә бер якка,
Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап,
Өянкеләр елап озата.

Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Читтә йөрсәк, шуңа күрәдер
Чишмә чыңлап, өянкеләр елап,
Таллар җырлап, төшкә керәдер.

Шушы якта безнең хезмәт калсын,
Мирас булып килер яшьләргә.
Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Шул туфракта язсын яшәргә!

# Әнкәйләр җыры

*Фәрит Хатипов* шигыре




Җилләр исә, җилләр исә,
Җилләр нидер сөйлиләр.
Ерак балачакта калган
Әнкәм җырын көйлиләр.


Көйлиләр дә, җырлыйлар да
Бик сагынган чакларда.
Җыр чакыра, җыр кайтара
Безне туган якларга.

Чакырган җыр, яраткан җыр
Йөрәктә урын ала.
Йөрәктә урын ала да
Гомергә истә кала.
Мәңгелеккә сөю булып
Әнкәйләр җыры кала.

Җилләр исә, җылы җилләр,
Җилләр нидер сөйлиләр.
Йөрәгемдә урын алган
Әнкәм җырын көйлиләр.

# *Сабан туе*

*Хәниф Хөснуллин* шигыре




Туганнар кайткан сагынып,
Ерактан дуслар килгән.
Сабан туе шулай безне
Чакыра бөтен илдән.

Кушымта:

Сабан туе, Сабан туе,
Изге бәйрәм илемдә.
Ак сөлгеләр уйнап тора
Көрәшчеләр билендә.

Уйната да, биетә ул,
Җырлата, гөрләштерә.
Сабан туе күңелләрне
Мәңгегә берләштерә.

Кушымта.

Сабан тургайлары җыры
Яңгыраган чакларда,
Илне иңләп бәйрәм килә
Безнең туган якларга!

Кушымта.

# Үкенү

*Динә Камалетдинова* шигыре




Юксынган чакларда,
Табынып хатларга,
Көттем бит мин сине, бик көттем.
Күрешер минутлар
Бик якын калганда,
Ятларга калдырып ник киттем?
Язмышым микән соң,
Ялгышым микән соң?
Соң инде, син мине чакырма.

Үткәнгә юл урау,
Күңелдә мең сорау,
Юк кире әйләнеп кайтырга.
Әле дә исемдә,
Гел күрәм төшемдә
Моң тулы сагышлы йөзеңне.
Үтсә дә күп еллар,
Акса да күп сулар,
Юк, гафу итмәмен үземне.

## *Сакладым сине күңелемдә*

*Гөлшат Зәйнашева* шигыре



Сакладым сине күңелемдә
Сагынуларыма төреп.
Гомергә бергә булсак та,
Туялмам кебек күреп.

Әйтче, иркәм, әллә юкмы
Сине сөяргә хакым?..
Син бит миңа күз керфегем,
Күз алмам кебек якын.

Саклармын сине күңелемдә
Сагынуларыма төреп.
Гомергә бергә булсак та,
Туялмам сине күреп.

## Күзләремнең төсе үзгәрмәде

*Нияз Акмал* шигыре

**Moderato**




Икәү бергә йөргән сукмакларда
Яфрак күмде безнең эзләрне.
Яфракларның төсе үзгәрмәде,
Яфракларның төсе үзгәрмәде,
Синнән башка күзләр үзгәрде.

Ак бураннар миңа кабатлады
«Мин яратам» дигән сүзләрне.
Бураннарның төсе үзгәрмәде,
Бураннарның төсе үзгәрмәде,
Синнән башка дөнья үзгәрде.

Синнән башка, дустым, синнән башка
Күп нәрсәләр инде үзгәрде.
Күзләремнең төсе үзгәрмәде,
Күзләремнең төсе үзгәрмәде,
Сагыш кына басты күзләрне…

# *Тәрәзәңдә утың бар*

*Нияз Акмал* шигыре



Бу дөньяда төрле хәл бар —
Ярату бар, оныту бар.
Сиңа киләм... Тәрәзәңдә,
Тәрәзәңдә утың бар.

Әле ярый, әле ярый
Тәрәзәңдә утың бар.


Бураннарда адаштырып,
Интектерде бу төннәр.
Сиңа киләм... Тәрәзәңдә,
Тәрәзәңдә утың бар.


Ярый әле, ярый әле
Тәрәзәңдә утың бар.

Бу дөньяда төрле хәл бар —
Ярату бар, оныту бар.
Тәрәзәңдәге уттан да
Якты янган өметем бар.
Сиңа киләм, әле ярый
Тәрәзәңдә утың бар.

## *Ак күл*

*Гыйлаҗ Минаев* шигыре






Ак күл өсләрендә ак томаннар
Күтәрелә таңнар атканда.
Сагынып кайтам
туган якларыма
Шомырт шаулап чәчәк атканда.


Яшьлегемә кайтам еллар аша,
Тугайларга, якты күлләргә.
Кубәләктәй очып,
гөлләр кочып
Менәр өчен яшел үрләргә.

Бүгенгедәй истә: үсмер чакта
Суларында чумып уйнадым.
Онытмам мин сине туган ягым,
Төнбоеклы ак күл буйларын.

## *Моңлану*

*Фәннур Сафин* шигыре






Тулган айга карап
Чәчләреңне тарат.
Моңсу җырлар, ләкин, җырлама.
Сиңа карыйм да мин,
Күзем ала алмыйм, —
Мин моңланмыйм, җаным моңлана...


Бердәнберем идең,
Син — бәхетем, дидем,
Үз бәхетеңә инде соңлама.
Ак моңнарым булып
Янадыр ай тулып, —
Мин моңланмыйм, йөрәк моңлана...

Юкка гына түгел,
Сагышлана күңел,
Ул ашкына ерак елларга.
Күз яшьләрен яшер,
Ара ерак хәзер,
Тик моңланма, күңел, моңланма...

Бу бит туган яктыр,
Тирә-ягың матур
Чыкмасаң да озын юлларга.
Тугайларга дәшеп
Җырлап килә яшьлек,
Шуңа күрә син дә моңланма!

# *Җилфер-җилфер җил искәндә*

*Әхмәт Ерикәй* шигыре




Җилфер-җилфер
җил искәндә
Дулкын уйный күлләрдә.
Иркәмне иркәлəгез, дип,
Үзем куштым җилләргә.


Җилфер-җилфер
җил искәндә
Бөркән зәңгәр шәлеңне.
Иртән искән язгы җилдән
Сора минем хәлемне.

Җилфер-җилфер
җил искәндә
Иелә-сыгыла бөдрә тал.
Җил шикелле кайттым, иркәм,
Тизрәк чыгып каршы ал.

Җилфер-җилфер
җил искәндә
Тынгы белми ак каен;
Сагынып кайттым, кил яныма,
Кил, кояшым, кил, аем!..

# Тыңла әле

*Марсель Гыймазетдинов* шигыре





Тыңла әле, бер моң ишетелә,
Ул моңны мин отып аламын.
Сагышларны
тизрәк басар өчен,
Кавышуны көтеп каламын.

Тыңла әле, бер моң ишетелә,
Ул моңнар бит чыга йөрәктән.
Язмышларны җиңеп,
шул ук моңнар
Яшәргә бит безне өйрәткән.

Тыңла әле, бер моң ишетелә,
Таныш алар, күптән, күптәнге;
Таныш моңнар аша сине көтәм,
Якын итә алмыйм бүтәнне.

# *Арча таулары*

*Дамир Гарифуллин* шигыре




Арча, диләр, Арча, диләр,
Арча биек тауларда.
Язмыш адәм балаларын
Йөртә әллә кайларда.

Их... Арча тауларыннан,
Меналмыйм алларыннан.
Тормыш җиле аермасын
Ярларын парларыннан.

Арча тавы матур булып
Күренә алсу таңнарда.
Сөю гөле беркайчан да
Сулмый гашыйк җаннарда.

# Эзләмә син минем сөюемне

*Гыйлемдар Рамазанов* шигыре





Эзләмә син минем сөюемне
Тик сүзләрдән, сәлам-хатлардан,
Күр син аны, карап күзләремә,
Икәү бергә булган чакларда.


Әйтелмәгән сүзләр әйтелгәннән
Кадерлерәк була түгелме?!
Тик син генә аңлый аласың бит
Әйтмәсәм дә, әйтер сүземне.


Сөюемне эзлә шатлыгымнан,
Сагынуымнан аны таба бел,
Эшләремнән, сулыш алуымнан,
Һәм үзең дә шулай яна бел!!!

# *Син кайчан кайтырсың*

*Илдар Юзеев* шигыре






Син киткән юлларда җәйләрен
Томаннар җәелә.
Син кайчан
кайтырсың нур булып
Чәчәкле җәемә?


Син киткән юлларда көзләрен
Яфраклар өзелә.
Син кайчан
кайтырсың ямь биреп
Ямансу көземә?

Син киткән юлларда кышларын
Җилгә кар кушыла.
Син кайчан
кайтырсың юл ярып
Буранлы кышыма?


## Кичер мине

*Мөхәррәм Каюмов* шигыре



## МОҢЛАНУ




Син су алган
салкын чишмәдә мин
Көн дә кичен атым эчерәм.
Эчә атым,
Эчтә татлы ялкын,
Үткәннәрне искә төшерәм.

Тау битендә синең чияләрең
Күптән инде бирде җимешен.
Чия кебек,
Нур балкытып көлеп,
Чыгарсың дип эзләп килешем.

Син тауларда салган
сукмакларда
Ал чәчәкләр үсә тезелеп.
Тирә-якта
Бары синең хакта
Былбыл сайрый монда өзелеп.

Хәтерлим дә,
рәхәт минутларның
Татлы ләззәтеннән исерәм.
Очрашыйк бер,
Ике килмәс гомер,
Кичер мине, мин дә кичерәм...

# Әнкәй җыры*

*Гөлшат Зәйнашева* шигыре




* Бу җыр Казан шәһәрендә үткәрелгән «Әнкәйләр җыры» конкурсында өченче урынга лаек булды.


Әнкәй һаман бер җыр җырлый да җырлый,
Әнкәй һаман бер җыр җырлый да җылый:
«Тәрәз төбем кызыл яран,— ди. —
Кайларда йөрисең, балам?!» — ди.


Армиягә китте абыем, солдатка,
Әнкәй җылый, килми, диеп, бер хат та.
«Тәрәз төбем кызыл яран,— ди. —
Кайларда йөрисең, балам?!» — ди.

Әнкәй шулай абыйны сагынып җырлый,
Өзлеп сагынып җырлый, җырлый да җылый…
«Тәрәз төбем кызыл яран,— ди. —
Кайларда йөрисең, балам?!» — ди.

# *Туган көнең белән*

*Шәмсия Җиһангирова* шигыре






Туган көнең синең бүген —
Дөньяга килгән көнең.
«Бу мин!» — диеп бар җиһанга
Шат хәбәр биргән көнең.

К у ш ы м т а :
Котлы булсын,
котлы булсын
Син дөньяга туган көн!
Зәңгәр күккә исемеңне
Кояш уеп куйган көн.

Рәхмәт әти-әниеңә,
Син булганга бу җирдә.
Иң изге теләкләр телим,
Дускаем сиңа мин дә.


К у ш ы м т а .


Булсын һәрчак җан юатыр
Иң кадерле дусларың.
Йөрәгеңдә дөрләп торсын
Мәңге яшәү учагың.

К у ш ы м т а .

# *Миләш*

*Харрас Әюп* шигыре







Өй түрендә миләш
Иелә җилләр тигәч,
Тәрәзәгә карап кызара;
Өзгәләнмә, миләш, —
Булчы якын сердәш
Мәхәббәтен көткән кызларга!

Язың-көзең димә,
Башкаеңны и дә,
Йөрәкләрен тыңла көн дә син!
Әйтмә таң җиленә,
Бел тик үзең генә, —
Ятлар берүк сизә күрмәсен.

Өй түрендә миләш…
Авыл берни белмәс.
Ник кызарган болай, димәсләр;
Яшерен яна-яна
Кулын болгап кала, —
Әллә кызлар, әллә миләшләр…

# *Гармунчыга*

*Никифор Тукмачев* шигыре




Кулларыңда тальян гармун,
Әйдәле бер тарт әле!
Уйнап үскән, җырлап киткән
Көйләрне сайрат әле!

«Шөгер», «Арча»ларны уйна,
«Шахта»ны, «Сарман»нарны.
Уйна, искә алыйк илгә
Кайталмый калганнарны.


Уйна, гармун, җаныбызны
Сагыш сарган көннәрдә.
Шушы моңнар алып кайта
Туган-үскән җирләргә.

Алып кайта, алып китә,
Качып булмый язмыштан.
Без генәме туган-үскән
Җирдән китеп ялгышкан?..

Урам көйләре хәзер дә
Колакта чыңлап тора.
Туган якларга кайтабыз,
Гармуннар тыңлап кына.

# *Ай, Дилә, Диләфрүз*

*Илнур Галимов* шигыре




Серледер күз карашларың,
Тирә-юньдә бер генә.
Барча егет гашыйк сиңа,
Сер бирмимен мин генә.

К у ш ы м т а :
Ай, Дилә, Диләфрүз,
Бөдрә чәчкәй, кара күз;
Гашыйк булам,
ахры, мин дә,
Йөрәккәем, зинһар, түз!

Оялмыйм да кебек үзем,
Күрсәм, телем бәйләнә.
Елмаеп карап куйса да,
Бөтен дөньям ямьләнә.


К у ш ы м т а .

Төннәр буе уйлыйм һаман,
Миңа насыйп яр микән?
Син булмасаң, бу дөньяның
Матурлыгы бар микән?!

К у ш ы м т а .

# Бармагымда йөзегең

*Фәнис Яруллин* шигыре




Бармагымда йөзегең,
Күпкә түгел, түз, дидең.
Сагынганда йөзегемә
Салгаларсың күз, дидең.

К у ш ы м т а :

Түзәм инде, түзәмен,
Өзелсә дә үзәгем.
Сагышларым
саргайтмасын,
Йөзегеңнең бизәген.

Бармагымда йөзегең,
Йөз салдым да, йөз кидем.
Сагышларымны басарга
Җитәр иде бер сүзең.

К у ш ы м т а .

Бармагымда йөзегең,
Кидергән идең үзең.
Бармагымдагы йөзектә
Чагыла нурлы йөзең.

К у ш ы м т а .

# *Курай уйный, курай җырлый**

*Фоат Галимуллин* шигыре




Курай уйный, курай җырлый,
Моң агыла, моң ташый.
Курай моңы күңелләргә,
Йөрәкләргә юл башы.

Дәртле, җитез, кыю да ул
Егет-кызлар кулында.
Сердәш-дуслар кирәк чакта,
Юлдаш — барыр юлында.

Йөрәк моңы, йөрәк сере —
Сыйдыра барын курай.
Күңелләрне җилкендерә,
Әйтерсең язгы тургай.

Ил өстендә курай моңы —
Тынычлык, дуслык җыры.
Күңелләр көр, күтәренке,
Яшәүнең матур чоры.


* Бу җыр «Курай» радиосының гимны итеп алынды.

# Авыл уртасында яшел чирәм

*Нияз Акмал* шигыре



# МОҢЛАНУ




Авыл уртасында яшел чирәм,
Чирәм өсләрендә сине күрәм,
Күзләремне йомсам аз гына.
Үләннәр дә шытты инде диеп,
Бәбкәләр дә чыкты инде диеп,
Тагын бер хат, әнкәй, яз миңа…

Авыл уртасында яшел чирәм,
Төшләремдә һаман сине күрәм.
Һаваларда оча тилгәннәр.
Ул тилгәннәр безнең бәбкәләрне,
Кайгыларга салып әнкәләрен,
Урлап китәр өчен килгәннәр.

Бәбкә саклап йөргән көннәреңдә
Каз мамыгы иде мендәреңдә,—
Күрмәдеңме аның килгәнен? —
Балаларын — газиз бәбкәләрен,
Сагышларга салып әнкәләрен,
Урлап китте язмыш тилгәне.

# Сәлам әйт, җил...

*Рөстәм Фәйзуллин* шигыре






Тугайларга сәлам әйт, җил,
Урманнарга сәлам әйт.
Тау башыннан ай калыкса,
Син аңа да сәлам әйт.

К у ш ы м т а:
Әйт син тагын,
мин кайтырмын,
Бәхетем калды шунда.
Туган ягым чакыруы
Торналар тавышында.

Әйт син сәлам, җәйләр буе
Кош сайраган талларга,
Канатыңны сыйпап бер уз
Мин яшәгән ярларга.

К у ш ы м т а.


Сәлам әйт син, болындагы
Сабантуй колгасына.
Бәлки, аның ал яулыгы
Җилферди булыр шунда.


К у ш ы м т а.

## *Соңгы сөюдер бу...*

*Тәслимә Хәләф* шигыре

**Tempo di valse**






Гомрем буе көттем бу сөюне,
Язмышымнан сорап, тилмереп.
Сары көздә сабыр гына көттем,
Язлар җитсә, көттем тилереп.

Кушымта:
Соңгы сөюдер бу — соңгы ялкын,
Кабатланмас сихри иртәләр!
Соңгы сагыштыр бу — соңгы ташкын,
Җан әрнемәс иде бу кадәр!

Юлларыңа гөлләр салып көттем,
Җитәрсең дип бөтен гомергә.
Ай нурыннан тукып япма тектем,
Бәхет — багалмамны төрергә.


Кушымта.

Чәчәкләрдән бишек үреп көттем,
Тирбәлергә бергә-гомергә...
Китәм, димә! Әйтмә! Китмә! Китмә!!
Андый яра салма бәгырьгә.

Кушымта.

# *Тик синдә күңел*

*Әхәт Сафиуллин* шигыре




«Син минеке!» — диеп,
Йөрим янып-көеп:
Тик синдә күңел,
Тик синдә күңел.
Синдәй гүзәл ярлар
Юктыр, юктыр алар.
Бу мөмкин түгел,
Бу мөмкин түгел.


Нур уйный йөзеңдә,
Белмисең үзең дә:
Елмаюың — ай,
Елмаюың — ай.
Серледер күзләрең,
Татлыдыр сүзләрең,
Булып кал шулай!
Булып кал шулай!

«Мин дә сөям!» — дисең,
Тик шуны әйтмисең:
Ник кавышмыйбыз?
Ник кавышмыйбыз?
Каршымы туганнар,
Ник шулай соң алар?
Бик сагышлы без...
Бик сагышлы без...


«Мин дә сөям!» — диеп,
«Янам-көям»,— диеп
Әйтә күзләрең,
Әйтә күзләрең.
Бәхет өмет итеп,
Кавышуны көтеп,
Күпме түзәрмен...
Күпме түзәрмен...

## Туган нигез

*Рафис Корбан* шигыре



# МОҢЛАНУ




Дөнья куып, мәшәкатьләр гизеп
Йөресәк тә әллә кайларда,
Оныттырып барлык борчуларны
Туган нигез дәшеп кайтара.

К у ш ы м т а:
Туган нигез,
эткәй корган нигез,
Бабамнардан калган
нигез син.
Һәммәбезне бердәй
тигезлисең,
Һәммәбезгә дә бертигез син.

Оясыннан очкан кошлар кебек
Без дә очтык канат кагынып.
Туган нигез, ерак-еракларда
Без яшибез сине сагынып.

К у ш ы м т а.

Еллар узган саен, кайта уйлар
Җылысына туган нигезнең.
Хәтерлисең булыр бала чакны,
Яшьлекләрне әле син безнең.

К у ш ы м т а.

# Сандугач сайрый авылда

*Роберт Миңнуллин* шигыре



Сандугач сайрый авылда —
Без яшәгән урында.
Сагынадыр авылның ул
Җыр язучы улын да.

Кушымта:

Сандугачның хисләре дә
Кайный минем эчемдә.
Сайрый ул
минем көйне дә,
Сайрый минем өчен дә.

Сандугачларга калдырып
Киттек туган якны да.
Кадерләрен белмәдек шул
Сандугачлар чаклы да.

Кушымта.

Сандугачның баласы да
Ташламый үз оясын.
Ә без менә ташлап киттек,
Ник беребез оялсын?


Кушымта.


Сайрап торган җиребезне
Сагынырбыз әле без.
Сандугач сайрый... барыбер
Җиңеләйми хәлебез.

Кушымта.

## Әллә язмышым, әллә ялгышым

*Фәүзия Бәйрәмова* шигыре






Әллә язмышым, әллә ялгышым —
Юллар чатында калдым ялгызым.
Калды сөюем, калды хатларың,
Калды яшьлектән моң-газапларым.


Кайтырсың диеп уйлаган идем,
Сөеп-сөелеп туймаган идем.
Язылган хатым җавапсыз калды,
Мәхәббәтемне чит берәү алды.

Әллә язмышың, әллә ялгышың,
Барыр юлыңда син дә ялгызың.
Әллә җырымны ишеттең инде,
Ләкин мәңгегә кичектең инде.

# *Кибәхуҗам – минем язмышым*

Рәмис Аймәт шигыре






Ерак-еракларга китсәм дә мин,
Чит җирләрдә озак йөремәм.
Туган туфракларны сагынып бер
Мин кайтырмын сиңа җыр белән.

Кибәхуҗам — минем сагышым,
Язмышым син, йөрәк кагышым.

Бормаланып аккан Макса суың
Йөрәгемнең китми түреннән.
Синең матурлыгың күңелемә
Сагыну җыры булып үрелгән.

Авылымда чыңлый гармуным,
Шунда туды минем бар моңым.

Кар-бураннар, яңгыр диеп тормам,
Мин кайтырмын сиңа ашкынып,
Тукаш күл буйлары басар микән
Сагыну хисләремнең ялкынын.

Туган авылым минем, сагышым,
Язмышым син, йөрәк кагышым.

# *Сары сагыш*

*Фәнис Яруллин* шигыре

**Andantino**






Сары сагыш, сары сагыш
Каеннарга тимә ялгыш,
Алар җирнең балкышлары,
Алар җирнең аккошлары.

Кушымта:
Сүндермә син
балкышларны,
Саргайтма син
аккошларны.
Җиңел түгел беркемнең дә
Бу дөньяда язмышлары.

Гөлләргә дә кагылма син,
Иңнәргә дә сарылма син.
Кит еракка, чит җирләргә,
Тимә, тимә күңелләргә.


Кушымта.


Сары сагыш, сары сагыш,
Тормыш — давыл, ә без — камыш.
Бәхет — кайгы арасында
Бара көрәш, бара тартыш.

Кушымта.


## Онытты, дип уйлый күрмә, җаный

*Әгъзәм Тимершин* шигыре










Онытты, дип уйлый күрмә, җаный,
Онытылмыйсың бер минутка да.
Синең өчен төшәр идем суга,
Керер идем янган утка да.


Онытты, дип уйлый күрмә, җаный,
Онытырга сине сәбәп юк.
Көне-төне күңелемдә һаман,
Сине уйламаган сәгать юк.

Онытты, дип уйлый күрмә, җаный,
Онытыламы яшьлек еллары?!
Әле һаман сине көтә күңел,
Сагыш тулы йөрәк кыллары.

## *Кайтам исәнлек теләп*

*Фәрит Хатипов* шигыре






Төштә күрәм әнкәемне,
Күрәм туганнарымны.
Очып кына кайтыр идем —
Сагынам туган ягымны.

К у ш ы м т а :

Сагындыра туган нигез,
Сандугачлы тал-тирәк.
Әнкәемә үзем бүләк —
Кайтам исәнлек теләп.

Бер күрешү — бер гомер, ди,
Соңарып кайтмыйм микән?
Тәрәз чирткән җылы җилләр
Ни хәбәр сөйли икән?

К у ш ы м т а .

Язлар килә, көзләр җитә,
Гомерләр бик тиз үтә.
Күпме гомерләр калгандыр,
Алда безне ни көтә?

К у ш ы м т а :

Сагындыра туган нигез,
Сандугачлы тал-тирәк.
Әнкәй миңа үзе бүләк —
Кайтам исәнлек теләп.

# *Тура буйларында*

*Мәхмүт Хөсәен* шигыре

**Andantino**




Тура буйларында таллар
Үрелеп үсә, диләр;
Төмән якларында ярлар
Үзәкне өзә, диләр.
Үзәкне өзә, диләр шул,
Бер карап үтсә, диләр;
Гомергә кала эзләре
Бер кабат үпсә, диләр.


Тура буйларында таңнар
Алланып ата, диләр.
Төмән якларында ярлар
Янып ярата, диләр.
Янып ярата, диләр шул,
Бик тиз карата, диләр.
Булсаң бул гомерлек иптәш,
Юкка шаяртма, диләр.

# *Туган җиргә мәдхия**

*Марсель Галиев* шигыре




* Бу җыр 2002 елда Мәскәүдә узган «Нәүруз моңнары» конкурсында дипломга лаек булды.




Үскәнбезме таралышыр өчен
Туган җирдән ерак-еракка.
Яшәсәк тә кайсы тарафларда,
Юллар тарта һаман шул якка.


Белгәнбезме чишмә суларының,
Диңгезләргә барып җитәсен.
Аккан сулар да бит кире кайта,
Кеше җаны кайтмый нишләсен.


Сизгәнбезме сагындырыр өчен
Араларны еллар бүләсен.
Юл чатында калган
сөйгән ярның,
Каен булып төшкә керәсен.

Сизгәнбезме юрамыйча гына,
Бәхет кошы кайда кунасын.
Соң аңлыйбыз,
бары туган җирдә
Ике гомер яшәп буласын.

# *Сәкинә ханым*

*Гөлшат Зәйнашева* шигыре







Син үстергән ап-ак розаларны
Шау чәчәктә, диләр көзен дә.
Әллә үзең роза чәчәкме син,
Сәкинә ханым?
Чәчәк елмаюы йөзеңдә.

Моңаясың кайчак, мөмкинме соң,
Гел елмаеп кына яшәргә?!
Акбүз атка менеп сөйгән ярың,
Сәкинә ханым,
Китте мәллә ерак сәфәргә?

Юк, моңайма, кайтыр сөйгән ярың,
Газиз башкайлары сау булсын.
Ул да сине синең кебек сөйсен,
Сәкинә ханым,
Синең сагыну белән сагынсын!

# *Айлы юл*

*Асия Юнысова* шигыре




Айны юлдаш иттем,  
Юлга чыгып киттем,  
Яшь наратлар йөгерә  
Каршыма.

К у ш ы м т а :

Ике кулың сузып,  
Ай нурларын узып,  
Үзең чыгып мине  
Каршыла!

Бик ашкындым быел,
Ай толымы бу юл.
Сиңа илтер мине,
Бергенәм.


Кушымта:
Көткәнеңне беләм,
Шуңа очып киләм,
Көтеп алыр кешем
Син генә.

Күреп туймам сине,
Яшьли сөйгәнемне.
Аерса да безне
Күп еллар.

Кушымта:
Күпме юллар үттем,
Барыбер сиңа илтте.
Ай нурлары төшкән
Бу юллар.

# Мин китәм, ә син каласың

*Заһид Мәхмүди* шигыре






Олы юлның тузаны ла...
Мин китмим андый юлдан.
Сагындыра гел авылым,
Сагындыра шул тузан.

К у ш ы м т а :

Авыл капкасына чыкма,
Мин китәм тимер юлдан.
Керфегеңә яшь кунмасын,
Кунмасын аңа тузан.

Мин китәм, ә син каласың,
Буласы инде булган.
Кайтасы күперләремне
Соңгы сүзләр яндырган.

К у ш ы м т а .


Олы юлның тузаны ла...
Тимердән чыкмый тузан.
Үксеп елый кош баласы,
Оясы инде тузган.


К у ш ы м т а .

# *Мәхәббәт ярасы*

*Ренат Харис* шигыре

**Allegretto**






Язларым ялгыз үттеләр,
Җәйләрем узып бара.
Бигрәк татлы сызлый икән
Мәхәббәт салган яра.

Кушымта:

Мин бит гел сине уйлыйм,
Якынлашырга кыймыйм.
Күзләребез очрашса да,
Эчемә шатлык сыймый.

Җәйләр юаныч бирмәде,
Гөлләрне сары сара...
Һаман тирәнәя генә
Мәхәббәт салган яра.


Кушымта.

Кышыма ялгыз керимме —
Син шуны уйлап кара.
Әҗәлдән дә яман икән
Мәхәббәт салган яра.

Кушымта.

# *Сарман юллары*

*Дамир Гарифуллин* шигыре




Сарман юллары сузыла
Җанымның кылларыдай.
Күңелдә кала уелып,
Җырларның юлларыдай.

К у ш ы м т а:

Әй, юлларым, юлларым ла,
Сездә гомер үтәдер.
Үткән гомер жәл түгел лә,
Күңел нидер көтәдер...

Сарман юлларына чыгып,
Кая да китеп була.
Юл булмаса гына бит ул
Дөньялар китек була.

Кушымта.

Сарман юллары чакыра,
Ягез, кемнәр юл чыга?
Бәхет кенә юлдаш булсын
Юллардагы юлчыга!


Кушымта.

Сарман юллары бормалы,
Чакрым саен тау гына.
Олысы да, кечесе дә
Йөрсен исән-сау гына.


Кушымта.

## Югалган балдак

*Нур Әхмәдиев* шигыре



## МОҢЛАНУ




Алтын балдаклар кидердең,
Күз салма, дип ятларга.
Балдак — вәгъдә билгесе ул,
Кирәк иде сакларга.

Кушымта:

Сизми калдым,
төшеп китте
Суга алтын балдагым.
Суга төшкән
балдагымны
Эзләп таба алмадым.

Яңа балдаклар алсаң да,
Никтер аны кимәдем.
Сине якын китермәдем,
Башкаларны сөймәдем.

Кушымта.

Ялгызлыкта үтә кичем,
Ялгыз үтә таңым да.
Күңелем тулы сагыну
Син булмагач янымда.

Кушымта.

Төшеп китте дә югалды
Бармагымнан балдагым.
Онытам дип, никләр инде
Үз-үземне алдадым?..

Кушымта.

# Кимә, кызым, әниеңнең күлмәген!

*Рәиф Бариев* шигыре




Кимә, кызым, әниеңнең күлмәген!
Хәтерләтмә аның яшьлек көннәрен.
Чишмә кебек челтер-челтер көлгәнен,
Болын буйлап йөгерә-йөгерә килгәнен.


Йөзләреңдә бар минем дә чалымнар,
Болай да бит син үзеңчә кадерле.
Кимә, кызым, әниеңнең күлмәген,
Телгәләмә, өзгәләмә бәгырьне.

Гел әниең инде синең йөзләрең,
Борыннарың, иреннәрең, күзләрең.
Кимә, кызым, әниеңнең күлмәген,
Хәтерләтмә, зинһар, яшьлек көннәрен...

# *Ялгыз уза гомер*

*Гөлшат Зәйнашева* шигыре






Аккан сулар кебек узып бара гомер,
Дулкын-дулкын икән гомер агышы да.
Ялгыз уза гомер, сине сагынып уза,
Нинди дәва табыйм йөрәк сагышыма?


Искән җилләр кебек узып бара гомер,
Җил-давыллы икән гомер агышы да.
Аерылышыр өчен кавышканбыз икән,
Әллә ничек булды безнең кавышу да.

Онтылган җыр кебек узып бара гомер,
Моңлы җырлар икән гомер агышы да.
Җырлый идек бергә, бармы, иркәм, хәзер,
Кушылып җырлар кешең моңлы тавышыңа?

# *Сагыну*

*Гәрәй Рәхим* шигыре






Җәйләр, кышлар, язлар сагындыра,
Газапларсыз үткән көннәрем.
Сагынамын иртә-кичләремне,
Сагынамын татлы төннәрем.

Кушымта:
Мин сагынып кына яшим хәзер,
Туган якны, өйне сагынам,
Дусларымны, яшьли сөйгәнемне,
Яшьли откан көйне сагынам.

Мәктәбемне, классташларымны,
Авылдашларымны сагынам.
Яшьлегемдә иңнәремә баскан
Авыр ташларымны сагынам.

Кушымта.


Сагынамын күптән вафат булган
Туган-тумачалар, картларны.
Әткәй-әнкәй әле исән булып,
Үзем тәпи йөргән чакларны.

Кушымта.

# *Кайтам әле, кайтам Сабаларга*

*Флера Тарханова* шигыре






Сабаларга искән йомшак җилләр
Сагыну җырым алып китегез,
Озын юлда аны югалтмыйча,
Әнием урамына илтегез!

К у ш ы м т а:
Шул урамда йөргән эзләрем бар,
Эзләремнән иңгән хисләрем бар.
Кайтам әле, кайтам Сабаларга —
Якын итеп әйтер сүзләрем бар.

Бала чакның иркә күз яшьләре
Тулган саен шунда тамгандыр.
Бәлки шуңадыр да бу гүзәл як
Күңелемә уелып калгандыр.


К у ш ы м т а:
Саба юлларында эзләрем бар,
Эзләремнән иңгән хисләрем бар.
Кайтам әле, кайтам Сабаларга —
Якын күреп әйтер сүзләрем бар.

Җилләреңә кушып җырлар юллыйм,
Сине сагынып, Саба яклары,
Рәнҗемә син миңа, күпме көтеп,
Кайтмады, дип, тагын кайтмады.

К у ш ы м т а:
Саба урамында эзләрем бар,
Эзләремнән иңгән хисләрем бар.
Кайтам әле, кайтам Сабаларга —
Якын күреп әйтер сүзләрем бар.

# Карлар ява

*Фәрдия Сәфәргалиева* шигыре




Карлар ява, карлар, карлар ява,
Карлар ява, күмә эзләрең.
Эзләреңә карап сине сагына,
Сине эзли минем күзләрем.


Карлар ява, күмә эзләреңне,
Яңа парлар килә эзеңнән.
Нинди дәва бар соң, әйтегезче,
Йөрәктәге сагыну хисеннән?..

Карлар ява, карлар, карлар ява,
Ап-ак карлар безнең эзләрдә.
Ап-ак кардай ап-ак сөюемнең
Мөлдерәмә яше күзләрдә...

# *Туганыма*

*Фирдания Гыйльфан* шигыре






Кайт, туганым, туган авылыңа,
Язгы кичләр калсын күңелдә.
Ташкыны да, болыты да газиз,
Нурлы кояш балкый күгендә.

К у ш ы м т а :

Кайт, туганым, туган авылыңа,
Туган як бит якын күңелгә.
Әткәй, әнкәй көтә безне анда,
Шөкер, исән алар бүгенгә.


Кайт, туганым, туган авылыңа,
Чишмә чыңын җыйна күңелгә.
Урманнарын, болыннарын буйла,
Мәңге сакла күңел түрендә.

К у ш ы м т а :

Кайт, туганым, туган авылыңа,
Туган як бит газиз күңелгә.
Әткәй, әнкәйләрнең хәтерен сакла,
Үкенмәслек булсын гомергә.

# *Мин сине югалттым*

*Галимҗан Гыйльманов* шигыре




Күпме еллар кичәм инде
Сагыш диңгезен.
Сине югалтып йөрим мин
Кичен, көндезен.

К у ш ы м т а :

Ай, Кояшта булсаң да,
Барыбер табачакмын.
Күккә ашып, үзем дә
Йолдыздай яначакмын!

Үземнеке иткәч кенә
Югалтып йөрим.
Табыл, иркәм, табыл инде,
Үзеңне күрим!


К у ш ы м т а .

Кайда йөрисең, сөеклем,
Бер генә күрен.
Күрү белән әйтер идем
Йөрәгем серен.

К у ш ы м т а .

# *Кайтып киләм*

*Камил Сәгадәт* шигыре




Офыкларга җитәр-җитмәс,
Туган җирдән китәр-китмәс
Саубуллаша иле белән
Кыр үрдәкләре.

К у ш ы м т а :
Кушылып
канат кагышына,
Моңсу кошлар тавышына
Тарала да өзә генә
Җыр үзәкләрне!

Кайтып киләм кыяр-кыймас,
Уч төбемә сыяр-сыймас
Тау астында — ал бишегем,
Болгарым минем.


К у ш ы м т а .

Күңелләргә кереп калган,
Бабамнарның тире тамган,
Гөлбакчалы туган илем —
Суларым, җирем.

К у ш ы м т а .

# Түземле булып кара

*Дания Галәми* шигыре




Су булып агып кара да
Ярларга кагып кара.
Ярдан-ярга бәрелгәндә
Түземле булып кара.

Кушымта:

Ай-Кояш булып кара да
Нурларың сибеп кара, —
Ай-Кояштай мәңге балкып,
Сүнми-сүрелми кара!

Җилләр булып кара да син,
Болытлар куып кара.
Болыт әйләнеп килүчән —
Чыдамың сынап кара.

Кушымта.


Болытлар булып кара да
Явымнар биреп кара.
Яшен-камчыңны уйнатып,
Йә, бер сызылып кара!..

Кушымта.

# *Шикләнмә сөюемә*

*Виниса Фәттахова* шигыре






Сөясеңме, дип сорыйсың,
Кая инде сөймәгән.
Көне-төне сине уйлыйм,
Минутым юк көймәгән.

Кушымта:
Шикләнмә,
ышан, бәгырем,
Ышан син сөюемә.
Синнән башка
беркемне дә
Яратмыйм, диюемә.

Сөясеңме, дип сорама,
Аңла күңелең белән.
Бер каравың җитә миңа
Нурлы күзләрең белән.


Кушымта.


Минем кебек
шулай сагынып,
Көтмидер беркем гел-гел.
Аңлатырга җитми сүзем,
Сөюемне үзең бел.

Кушымта.

# Көзге җыр

*Сафуан Әлибай* шигыре






Тәүге яфрак кыштырдагач
Кошкайлар китә икән,
Ә күңелләр киткәннәрне
Көтә дә көтә икән.

К у ш ы м т а:
Нигә юллар безне күптән
Табыштырмаган икән?
Табыштыргач, нигә генә
Кавыштырмаган икән?

Җилләр урман-кырларымны
Сарыга сабыштыра;
Шаулап килгән язларымны
Көзләргә авыштыра.


К у ш ы м т а.


Үтеп киткән көннәреңә
Кайтулар мөмкин түгел.
Киткән кошларны тагын да
Көтә дә көтә күңел.

К у ш ы м т а.

## Җырлый-җырлый ява тәңкә карлар

*Дилә Булгакова* шигыре






Кош мамыгы кебек карлар ява,
Чәчләремә кунып нурлана.
Адашасым килә кар яуганда
Синең белән ап-ак урамда.

Ялгыз калган мәлдә
тыңла тынып,
Онытылып тыңла
кар җырын!
Өшемәссең әле
кар яуганда,
Кар җырында калды
бар җылым.

Җырлый-җырлый ява
тәңкә карлар,
Иңнәремә төшеп
сарыла.
Ниләр булды икән
бу карларга,
Кемнәрне соң алар
сагына?!

# *Сөембикә чишмәсе*

*Кави Латыйп* шигыре

**Andantino**




Чишмә эзлим, чишмә эзлим,
Ханбикәнең чишмәсен.
Сөембикә эчкән суны
Бик тә килә эчәсем.

К у ш ы м т а :

Челтер-челтер ишетелә
Кайнар чишмә агышы.
Ул чишмәнең тавышында
Сөембикә сагышы.

Челтерәп аккан чишмәгә
Моң-зарларын сөйләгән.
Аккан суларга кушылып
Милли көйләр көйләгән.
К у ш ы м т а .


Агым суның тавышларын
Айлы кичтә тыңлаган.
Казан-йортка һәм халкына
Ак бәхетләр юраган.
К у ш ы м т а .

Ул чишмәне орышларда
Ятлар килеп шартлаткан.
Җир астыннан чишмә булып
Аккан гүя кайнар кан.

К у ш ы м т а :
Әле һаман ишетелә
Кайнар чишмә агышы.
Ул чишмәнең тавышында
Сөембикә сагышы.

## *Абау, Аллам, уф инде*

*Шәмсия Җиһангирова* шигыре



Абау, Аллам, уф инде,
Китәм, бәгърем, хуш инде.
Берьялгызың каласың,
Инде кемгә карарсың
Күңелләрең тулганда?


Абау, Аллам, аһ кына,
Сабыр итәм чак кына,
Карап торыйм китмичә,
Ничек китим көтмичә
Чын, дөрес җавапларын.

Чын, дөрес җавапларын
Үзем эзләп тапмадым,
Син әйт, белсәң, көттермә
Кем мин синең өченгә:
Бакыймы, вакытлымы.

Шундый хисләр татыймы
Синең дә күңелләрең.
Яндырган, көйдергәнең
Минекенә охшашмы,
Бәгырем, сөюләрең?!

# *Көнләмә. Көттермә. Соңлама.*

*Шәмсия Җиһангирова* шигыре






Көнләмә син мине, көнләмә
Чәчемнән сыйпаган җилгә дә.
Юк кына хәлне дә бар итеп
Үпкәләр сәбәпләр эзләмә.

К у ш ы м т а :

Эзләмә, бер бөртек кара тап
Тапмассың
саф-чиста күңелемнән.
Һәр уем, һәр эшем-гамәлем
Бер синең исемгә төрелгән.

Көттермә, килер дип, яратса,
Үзең кил йөгереп бер генә.
Уйларым уралган гел сиңа,
Хисемдә-исемдә син генә.


К у ш ы м т а .

Бер синең өченгә таңымда
Күз ачам бу якты дөньяга,
Ут сүнәр дә төшәр, караңгы,
Көнләмә. Көттермә. Соңлама.

К у ш ы м т а .

# *Могҗиза идең*

*Рәшит Шиһап* шигыре




Һаваларда нурлар,
нурга коена урман,
Үләннәре билдән киң алан.
Хуш исләрен сулап
чәчәкләрнең
Сөенә-көенә йөрим мин һаман.


Кинәт пәйда булдың.
Аһ, син нинди идең —
Күзне алалмаслык сөйкемле!
Бар чәчәкнең матурлыгын
җыйган
Гүзәллекнең үзе шикелле!

Һаваларда нурлар,
Индә синең куллар.
Мин аңладым: син бит, син — риза!..
...Еллар аша безне яшәртә күк
Искә төшеп шушы могҗиза.

# Әткәй юлыннан

*Фирдания Гыйльфан* шигыре






Әткәй миңа пар ат бирде,
Иярлә дә чап, диде.
Эшсез торма, ярсыз калма,
Үз юлыңны тап, диде.

Кушымта:

Кышкы юлдан ярсып чаба
Җилдәй җитез атларым.
Ярны ятка бирмәс өчен
Янып-көйгән чакларым.

Рухым көчле, беләгем нык,
Үземә тиң яр таптым.
Әткәй сүзен хакладым да
Дилбегәне нык тарттым.


Кушымта.


Атлар елгыр, дилбегәне
Ычкындырмам кулымнан.
Әткәй сүзе колагымда,
Атлыйм әткәй юлыннан.

Кушымта.

## *Мин халкым белән бергә*

*Әхмәт Ерикәй* шигыре






Әнкәй мине кырда тапкан,
Табигать кочагында.
Кендек әбие булмаган
Минем туган чагымда.
Түмгәк миңа мендәр булган,
Түшәк булган яшь үлән.
Әнкәй минем битне юган
Үлән чыклары белән.


Ефәк нурын биләү итеп
Кояш мине биләгән.
Тургай минем баш өстемдә
Бишек көен көйләгән.
Чәчәкләрнең хуш исенә
Җил туендырган мине.
Юрган кебек, яфрак җәеп,
Җир көтеп торган мине.

Шуның өчен җир дигәндә
Кырыслардан кырыс мин.
Кул күтәрсәләр җиремә,
Кул өзүче кылыч мин.
Җирем минем алтын тәхет,
Җирем минем гөлбостан.
Җырламасам шул хакта мин,
Ятим төсле тормыштан.

# *Даниям*

*Раил Сәләх* шигыре






Дулкынланам, бәгърем, тыңла йөрәгемне,
Тыңла, зинһар, бик соң булса да.
Синңа гына булган тәүге мәхәббәтем
Сүрелмәде еллар узса да.

К у ш ы м т а :
Бик ямансу чакта болыннарга барам,
Сандугачлар белән серләшәм.
Сагынган көннәрдә, төннәрен саташып
Даниям, дип, сиңа эндәшәм.

Узды, узды еллар, акты күпме сулар,
Гомерем буе сине көттем мин.
Һаман синсез яшәү газапларын татып
Язмыш сынавына түздем мин.

К у ш ы м т а .

Саф мәхәббәт назын мәңге татый алмый
Яшәүчеләр әле азмыни?
Язмышыңаниләр язган булса, шуны
Күрерсең дигәннәр хакмыни?

К у ш ы м т а .

## *Көттермәгез...*

*Мансур Шиһапов* шигыре






Язын юлда парын җуйган
Бер сандугач тирәктә,
Кичтән таңга кадәр сайрап,
Ялкын өсти йөрәккә.

К у ш ы м т а :

Сандугач кебек өзелеп
Сагынмыйбыз кайсыбыз,
Көтегез, дип
киткән җаннар,
Көттермәгез, кайтыгыз.

Тирәкләрне тибрәндереп
Канатын кага иртән,
Күңел серен уртаклашып
Киңәшләр сорый җилдән.

К у ш ы м т а .

Ай нуры белән бергәләп
Юлларны айкый-айкый,
Керфегеннән тамган яшь тә
Сагышын баса алмый.

К у ш ы м т а .


Шомыртлар ак шәлен япкан,
Сиреньнәр чәчәк аткан.
Юлда югалган сандугач
Яшьлеген эзләп тапкан.

К у ш ы м т а:

Сандугач күк кавышырга
Хыялланмый кайсыбыз.
Көткәннәргә бик тә авыр,
Көттермәгез, кайтыгыз!

## *Иң зур бәхет*

*Фирая Зыятдинова* шигыре



Җаның-тәнең биреп эшләр эшең булса,
Эштән сине сагынып көтәр кешең булса,
Иң зур бәхет менә шул ул дөньяларда.


Йөзләреңне сары сагыш киптермәсә,
Бала-чагаң сиңа хәсрәт китермәсә,
Иң зур бәхет менә шул ул дөньяларда.


Баш очында балкып торган күгең булса,
Алда сине көтеп торган үрең булса,
Иң зур бәхет менә шул ул дөньяларда.

Өйдә җылы түрең, нык нигезең булса,
Һәрчак җаның тыныч, сау-сәламәт булсаң,
Иң зур бәхет менә шул ул дөньяларда.

# *Туган көнең белән, әнкәем!*

*Фирдания Гыйльфан* шигыре






Рәхмәт, әнкәй, фатиханңы бирдең,
Ак биләүгә безне биләдең.
Канатланып көнне-төнне белми
Бишек җыры җырлап көйләдең.

Кушымта:

Әнкәй, бәгърем, яшә йөзгә кадәр,
Әй, сөеклем, йөз яшь аз булыр!
Гөлләр түгел, җырлар бүләк итәм,
Җыр мәңгелек, гөлләр тиз сулыр.

Тәбриклимен туган көнең белән,
Шөкер, әнкәй, бәйрәм мөбарәк.
Назлап кочам, үбәм битләреңнән,
Син булганга бәхетем түгәрәк.

Кушымта.

Бәхет юрап килер көннәреңә
Ниләр телим икән, әнием?
Йөрәк парәм минем, газизкәем,
Мин һаман да синең бәбиең.

Кушымта.

# Яшик әле сөенеп

*Камил Сәгадәт* шигыре



Ходай биргән исәнлеккә
Яшик әле сөенеп.
Ямен җибәрмик тормышның
Юк-барга да көенеп.

Кушымта:

Игелекләр юлдаш булсын!
Гомерләр бик тиз үтә.
Юлың туры, күңелең ак
Булуларга ни җитә.

Тигез яратылмаган бит
Хәтта кул бармаклары,
Тугры җанны күбрәк сыный
Дөньяның газаплары.


Кушымта.

Ямен җибәрмик тормышның
Юк-барга да көенеп.
Ходай биргән гомерләргә
Яшик әле сөенеп.

Кушымта.

## Үчекләмә, кояшкаем!

*Кәүсәрия Нуруллина* шигыре



Җылы яңгыр явып узган,
Мин барам урам буйлап.
Авылымның саф һавасын
Һич туя алмыйм сулап.

К у ш ы м т а :

Зәңгәр күктә кояш көлә:
— Кайттыңмы? — дия-дия.
Читтә яшәгәнгә мине
Үчекли сыман, гүя.

Үчекләмә, кояшкаем!
Болай да әрни йөрәк.
Туган авыл, газиз җирләр
Безгә кайда да кирәк!

К у ш ы м т а .

Барам авылым урамыннан,
Шул ук йортлар, шул ук тау.
Күреп үскән танышларым
Булса икән исән-сау.


К у ш ы м т а .


Җылы яңгыр явып узган,
Мин барам урам буйлап.
Иңнәремә канат куйган
Әткәм-әнкәмне уйлап.

К у ш ы м т а .

## *Хат язармын, дигән идең*

*Роберт Миңнуллин* шигыре






Хат язармын, дигән идең,
Тормадың бит сүзеңдә.
Көтүләрем юкка гына...
Хатың да юк, үзең дә.

К у ш ы м т а :

Хатларыңны көтмим инде,
Ни файда соң көткәннән?..
Күпме көтсәм дә, хатларың
Килмәс инде үткәннән.

Хат язармын дигән идең,
Язмадың бит, язмадың.
Хатларыңны көтә-көтә,
Узды ничә язларым.

К у ш ы м т а .

Хат язармын дигән идең,
Килмәде бит бер хат та.
Сәламеңне хәтта җилләр
Китермәде бер кат та.

К у ш ы м т а .

# *Эчтәлек*

*Автор турында* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3

Ярый ла син бар, туган як. *М.Хәбибуллин* шигыре . . . . . . . . 4
Синең нурың. *Х.Туфан* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Һаман яратам. *Зөлфәт* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Гөлнарым. *Г.Афзал* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Мәхәббәт сагышы. *Татар халык* сүзләре . . . . . . . . . . . . . 8
Сау бул инде. *Р.Вәлиев* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Авыл кызы. *Д.Хәбибуллин* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Яшәрәсең, Казан, яңарасың. *Г.Зәйнашева* шигыре . . . . . . . . 12
Теләче. *Г.Зәйнашева* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Шулай шул. *Р.Миңнуллин* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Гомер бер генә килә ул. *Т.Сәетҗанов* шигыре, *З.Нури* тәрҗемәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Газинур урманы. *Г.Зәйнашева* шигыре . . . . . . . . . . . . . . 18
Таңсылу. *М.Хөсәен* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Себер җирләре — илнең бизәге. *М.Миншин* шигыре . . . . . . . 21
Шушы яктан, шушы туфрактан без. *К.Булатова* шигыре . . . . . 23
Әнкәйләр җыры. *Ф.Хатипов* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . 24
Сабан туе. *Х.Хөснуллин* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Үкенү. *Д.Камалетдинова* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Сакладым сине күңелемдә. *Г.Зәйнашева* шигыре . . . . . . . . . 27
Күзләремнең төсе үзгәрмәде. *Н.Акмал* шигыре . . . . . . . . . 28
Тәрәзәңдә утың бар. *Н.Акмал* шигыре . . . . . . . . . . . . . 29
Ак күл. *Г.Минаев* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Моңлану. *Ф.Сафин* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Җилфер-җилфер җил искәндә. *Ә.Ерикәй* шигыре . . . . . . . . . 33
Тыңла әле. *М.Гыймазетдинов* шигыре . . . . . . . . . . . . . . 34
Арча таулары. *Д.Гарифуллин* шигыре . . . . . . . . . . . . . . 35
Эзләмә син минем сөюемне. *Г.Рамазанов* шигыре . . . . . . . . 36
Син кайчан кайтырсың. *И.Юзеев* шигыре . . . . . . . . . . . . 37
Кичер мине. *М.Каюмов* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
Әнкәй җыры. *Г.Зәйнашева* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . 40
Туган көнең белән. *Ш.Җиһангирова* шигыре . . . . . . . . . . . 41
Миләш. *Х.Әюп* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42
Гармунчыга. *Н.Тукмачев* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Ай, Дилә, Диләфрүз. *И.Галимов* шигыре . . . . . . . . . . . . 45
Бармагымда йөзегең. *Ф.Яруллин* шигыре . . . . . . . . . . . . 46
Курай уйный, курай җырлый. *Ф.Галимуллин* шигыре . . . . . . . 47
Авыл уртасында яшел чирәм. *Н.Акмал* шигыре . . . . . . . . . . 48
Сәлам әйт, җил... *Р.Фәйзуллин* шигыре . . . . . . . . . . . . . 50
Соңгы сөюдер бу... *Т.Хәләф* шигыре . . . . . . . . . . . . . . 51
Тик синдә күңел. *Ә.Сафиуллин* шигыре . . . . . . . . . . . . . 53

Туган нигез. *Р.Корбан* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Сандугач сайрый авылда. *Р.Миңнуллин* шигыре . . . . . . . . . . 56
Әллә язмышым, әллә ялгышым. *Ф.Бәйрәмова* шигыре . . . . . . . 57
Кибәхуҗам — минем язмышым. *Р.Аймәт* шигыре . . . . . . . . 59
Сары сагыш. *Ф.Яруллин* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
Онытты, дип уйлый күрмә, җаный. *Ә.Тимершин* шигыре . . . . . 62
Кайтам исәнлек теләп. *Ф.Хатипов* шигыре . . . . . . . . . . . . . . 63
Тура буйларында. *М.Хөсәен* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
Туган җиргә мәдхия. *М.Галиев* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
Сәкинә ханым. *Г.Зәйнашева* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Айлы юл. *А.Юнысова* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
Мин китәм, ә син каласың. *З.Мәхмүди* шигыре . . . . . . . . . . . 70
Мәхәббәт ярасы. *Р.Харис* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Сарман юллары. *Д.Гарифуллин* шигырез . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Югалган балдак. *Н.Әхмәдиев* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
Кимә, кызым, әниеңнең күлмәген! *Р.Бариев* шигыре . . . . . . . . 76
Ялгыз уза гомер. *Г.Зәйнашева* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
Сагыну. *Г.Рәхим* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79
Кайтам әле, кайтам Сабаларга. *Ф.Тарханова* шигыре . . . . . . . . 81
Карлар ява. *Ф.Сәфәргалиева* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
Туганыма. *Ф.Гыйльфан* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
Мин сине югалттым. *Г.Гыйльманов* шигыре . . . . . . . . . . . . . 86
Кайтып киләм. *К.Сәгадәт* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
Түземле булып кара. *Д.Галәми* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Шикләнмә сөюемә. *В.Фәттахова* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . 89
Күзге җыр. *С.Әлибай* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
Җырлый-җырлый ява тәңкә карлар. *Д.Булгакова* шигыре . . . . 91
Сөембикә чишмәсе. *К.Латыйп* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
Абау, Аллам, уф инде. *Ш.Җиһангирова* шигыре . . . . . . . . . . . 94
Көнләмә. Көттермә. Соңлама. *Ш.Җиһангирова* шигыре . . . . . . 95
Могҗиза идең. *Р.Шиһап* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Әткәй юлыннан. *Ф.Гыйльфан* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . 98
Мин халкым белән бергә. *Ә.Ерикәй* шигыре . . . . . . . . . . . . . 99
Даниям. *Р.Сәләх* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101
Көттермәгез. *М.Шиһапов* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
Иң зур бәхет. *Ф.Зыятдинова* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Туган көнең белән, әнкәем. *Ф.Гыйльфан* шигыре . . . . . . . . . 105
Яшик әле сөенеп. *К.Сәгадәт* шигыре . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
Үчекләмә, кояшкаем! *К.Нуруллина* шигыре . . . . . . . . . . . . . 108
Хат язармын, дигән идең. *Р.Миңнуллин* шигыре . . . . . . . . . . 109